**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О научно-образовательном центре мирового уровня в Республике Татарстан

В соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации от 30 апреля 2019 года № 537 «О мерах государственной поддержки научно-образовательных центров мирового уровня на основе интеграции образовательных организаций высшего образования и научных организаций и их кооперации с организациями, действующими в реальном секторе экономики» **постановляю**:

1. Создать научно-образовательный центр мирового уровня в Республике Татарстан (далее – Центр).

2. Определить, что Центр является объединением без образования юридического лица федеральных государственных образовательных организаций высшего образования и научных организаций с организациями, действующими в реальном секторе экономики.

3. Определить состав участников Центра по согласованию с ними (приложение № 1).

4. Установить, что Центр является открытым для вступления новых участников.

5. Утвердить Положение о Наблюдательном совете Центра (приложение № 2) и его состав (приложение № 3).

6. Предложить открытому акционерному обществу «Татнефтехиминвест-холдинг» осуществлять организационно-техническое обеспечение деятельности Наблюдательного совета Центра, а также функции координатора и сетевого интегратора взаимодействия его участников.

7. Министерству образования и науки Республики Татарстан совместно с открытым акционерным обществом «Татнефтехиминвест-холдинг» разработать и внести на рассмотрение Наблюдательного совета Центра предложения по:

составу и регламенту деятельности проектного офиса Центра;

составу и положению Управляющего совета Центра;

определению некоммерческой организации – получателя гранта в форме субсидий из федерального бюджета на оказание государственной поддержки научно-образовательным центрам мирового уровня на основе интеграции образовательных организаций высшего образования и научных организаций и их кооперации с организациями, действующими в реальном секторе экономики.

8. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
24 февраля 2020 года
№ УП-115

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «24» февраля 2020 года

№ УП-115

**Состав**
**участников научно-образовательного центра мирового уровня**
**в Республике Татарстан**

1. Федеральное государственное автономное образовательное учреждение высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет».
2. Федеральное государственное бюджетное образовательное учреждение высшего образования «Казанский государственный аграрный университет».
3. Федеральное государственное бюджетное образовательное учреждение высшего образования «Казанский государственный архитектурно-строительный университет».
4. Федеральное государственное бюджетное образовательное учреждение высшего образования «Казанская государственная академия ветеринарной медицины имени Н.Э. Баумана».
5. Федеральное государственное бюджетное образовательное учреждение высшего образования «Казанский государственный медицинский университет» Министерства здравоохранения Российской Федерации.
6. Федеральное государственное бюджетное образовательное учреждение высшего образования «Казанский государственный энергетический университет».
7. Федеральное государственное бюджетное образовательное учреждение высшего образования «Казанский национальный исследовательский технологический университет».
8. Федеральное государственное бюджетное образовательное учреждение высшего образования «Казанский национальный исследовательский технический университет им. А.Н. Туполева – КАИ».
9. Федеральное государственное бюджетное учреждение науки «Федеральный исследовательский центр «Казанский научный центр Российской академии наук».

10. Казанская государственная медицинская академия – филиал федерального государственного бюджетного образовательного учреждения дополнительного профессионального образования «Российская медицинская академия непрерывного профессионального образования» Министерства здравоохранения Российской Федерации.

11. Государственное научное бюджетное учреждение «Академия наук Республики Татарстан».

12. Ассоциация «Некоммерческое партнерство «Камский инновационный территориально-производственный кластер».

13. Ассоциация предприятий и промышленников Республики Татарстан (региональное объединение работодателей).

14. Акционерное общество «Научно-исследовательский институт по нефтепромысловой химии».

15. Акционерное общество «НЭФИС КОСМЕТИКС» – Казанский химический комбинат имени М.Вахитова (мыловаренный и свечной завод № 1 бывших Крестовниковых).

16. Акционерное общество «Особая экономическая зона промышленно-производственного типа «Алабуга».

17. Акционерное общество «Связьинвестнефтехим».

18. Акционерное общество «ТАИФ».

19. Акционерное общество «ТАНЕКО».

20. Акционерное общество «Татхимфармпрепараты».

21. Акционерное общество «Татэнерго».

22. Акционерное общество «Татэнергосбыт».

23. Открытое акционерное общество «Сетевая компания».

24. Открытое акционерное общество «Татнефтехиминвест-холдинг».

25. Казанское публичное акционерное общество «Органический синтез».

26. Публичное акционерное общество «КАМАЗ».

27. Публичное акционерное общество «Нижнекамскнефтехим».

28. Публичное акционерное общество «Татнефть» имени В.Д. Шашина.

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан
от «24» февраля 2020 года
№ УП-115

**Положение**
**о Наблюдательном совете научно-образовательного центра мирового уровня в Республике Татарстан**

1. Общие положения

1.1. Наблюдательный совет научно-образовательного центра мирового уровня в Республике Татарстан (далее – Наблюдательный совет) является коллегиальным совещательным органом управления научно-образовательным центром мирового уровня в Республике Татарстан (далее – Центр).

1.2. В своей деятельности Наблюдательный совет руководствуется федеральным законодательством, законодательством Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

2. Основные задачи и функции Наблюдательного совета

2.1. Основными задачами Наблюдательного совета являются осуществление общего руководства деятельностью Центра и определение программы его деятельности.

2.2. Наблюдательный совет для решения возложенных на него основных задач осуществляет следующие функции:

утверждение программы деятельности Центра, а также внесение в нее в установленном порядке изменений и контроль за ее выполнением;

мониторинг реализации программы деятельности Центра;

утверждение положения об Управляющем совете Центра и его состава, определение порядка формирования, задач и функций иных консультативных и совещательных органов Центра;

утверждение ежегодного отчета о реализации программы деятельности Центра и достижении показателей ее эффективности;

иные функции, предусмотренные программой деятельности Центра.

2.3. В целях осуществления своих функций Центр имеет право создавать проектные офисы и иные рабочие группы.

## 3. Организация деятельности Наблюдательного совета

3.1. Состав Наблюдательного совета формируется из числа представителей федеральных органов исполнительной власти, органов государственной власти Республики Татарстан, образовательных организаций высшего образования, научных организаций и организаций, действующих в реальном секторе экономики.

3.2. В состав Наблюдательного совета входят председатель Наблюдательного совета, заместители председателя Наблюдательного совета, секретарь Наблюдательного совета и члены Наблюдательного совета, осуществляющие свою деятельность на общественных началах.

3.3. Наблюдательный совет возглавляет председатель Наблюдательного совета – Президент Республики Татарстан (далее – председатель).

3.4. Заседания Наблюдательного совета созываются секретарем Наблюдательного совета по поручению председателя. Заседания Наблюдательного совета проводятся по мере необходимости, но не реже одного раза в год.

3.5. Заседания Наблюдательного совета проводятся в очной форме. Заседание Наблюдательного совета может проводиться с использованием систем видео-конференц-связи.

3.6. Заседание Наблюдательного совета считается правомочным, если на нем присутствуют более половины его членов.

3.7. Повестка заседания Наблюдательного совета формируется с учетом предложений членов Наблюдательного совета.

3.8. Секретарь Наблюдательного совета не позднее 20 дней до даты проведения заседания Наблюдательного совета представляет председателю проект повестки заседания Наблюдательного совета, документы и информационные материалы по вопросам повестки заседания.

3.9. Утвержденная председателем повестка заседания Наблюдательного совета, а также документы и информационные материалы по вопросам повестки заседания не позднее 10 дней до даты проведения заседания рассылаются членам Наблюдательного совета.

3.10. В заседаниях Наблюдательного совета с правом совещательного голоса принимают участие приглашенные эксперты, а также члены Управляющего совета Центра.

3.11. Решения на заседании Наблюдательного совета принимаются большинством голосов его членов, присутствующих на заседании, путем открытого голосования. В случае равенства голосов решающим является голос председателя.

3.12. Передача полномочий Наблюдательного совета Управляющему совету Центра, иным органам и лицам не допускается.

## 4. Порядок оформления решений Наблюдательного совета

4.1. Решения Наблюдательного совета, принятые на его заседании, оформляются протоколом.

4.2. Протокол заседания Наблюдательного совета ведется секретарем Наблюдательного совета и подписывается председателем и секретарем Наблюдательного совета. Мнение члена Наблюдательного совета, голосовавшего против принятого решения, по его требованию заносится в протокол заседания Наблюдательного совета.

4.3. Протокол заседания Наблюдательного совета составляется не позднее пяти дней с даты проведения заседания.

4.4. В протоколе заседания Наблюдательного совета указываются:

дата, время и место проведения заседания;

сведения о лицах, присутствовавших на заседании, и лицах, участвовавших в заседании путем использования систем видео-конференц-связи;

повестка заседания;

результаты голосования по каждому вопросу повестки заседания;

сведения о лицах, проводивших подсчет голосов;

сведения о лицах, голосовавших против принятия решения Наблюдательного совета и потребовавших внести запись об этом в протокол;

принятые решения.

4.5. Хранение оригиналов протоколов заседаний Наблюдательного совета обеспечивает секретарь Наблюдательного совета. Протоколы нумеруются в хронологическом порядке, формируются в отдельное дело и являются документами, содержащими информацию ограниченного доступа.

4.6. Копии протоколов заседаний Наблюдательного совета рассылаются секретарем Наблюдательного совета председателю и членам Наблюдательного совета, а также в Управляющий совет Центра не позднее 10 дней с даты проведения заседания Наблюдательного совета.

4.7. Секретарь Наблюдательного совета подготавливает, подписывает и рассылает выписки из протоколов заседаний Наблюдательного совета представителям Центра, реализующим выполнение соответствующих решений Наблюдательного совета.

---

Приложение № 3
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «24» февраля 2020 года

№ УП-115

**Состав**
**Наблюдательного совета научно-образовательного центра мирового уровня в Республике Татарстан**

| | |
|---|---|
| Минниханов Рустам Нургалиевич | Президент Республики Татарстан, председатель Наблюдательного совета |
| Боровская Марина Александровна | заместитель Министра науки и высшего образования Российской Федерации, заместитель председателя Наблюдательного совета (по согласованию) |
| Песошин Алексей Валерьевич | Премьер-министр Республики Татарстан, заместитель председателя Наблюдательного совета |
| Яруллин Рафинат Саматович | генеральный директор открытого акционерного общества «Татнефтехиминвест-холдинг», секретарь Наблюдательного совета (по согласованию) |
| Бурганов Рафис Тимерханович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр образования и науки Республики Татарстан |
| Гайзатуллин Радик Рауфович | министр финансов Республики Татарстан |
| Гафуров Ильшат Рафкатович | ректор Казанского (Приволжского) федерального университета, председатель Совета ректоров высших учебных заведений Республики Татарстан (по согласованию) |
| Зяббаров Марат Азатович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Каримов Альберт Анварович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр промышленности и торговли Республики Татарстан |
| Когогин Сергей Анатольевич | генеральный директор публичного акционерного общества «КАМАЗ» (по согласованию) |
| Маганов Наиль Ульфатович | генеральный директор публичного акционерного общества «Татнефть» имени В.Д. Шашина (по согласованию) |
| Садыков Марат Наилевич | министр здравоохранения Республики Татарстан |
| Салахов Мякзюм Халимулович | президент Академии наук Республики Татарстан (по согласованию) |
| Синяшин Олег Герольдович | директор Федерального исследовательского центра «Казанский научный центр Российской академии наук» (по согласованию) |
| Сорокин Валерий Юрьевич | генеральный директор акционерного общества «Связьинвестнефтехим» (по согласованию) |
| Хайруллин Айрат Ринатович | министр цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан |
| Шагиахметов Мидхат Рафкатович | министр экономики Республики Татарстан |
| Шадриков Александр Валерьевич | министр экологии и природных ресурсов Республики Татарстан |
| Шигабутдинов Руслан Альбертович | генеральный директор акционерного общества «ТАИФ» (по согласованию) |

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәге турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Югары белем бирү мәгариф оешмаларының һәм фәнни оешмаларның берләшүе һәм аларның икътисадның реаль секторында эшләүче оешмалар белән бергәләп гамәл кылуы нигезендә дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәкләренә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2019 елның 30 апрелендәге 537 номерлы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәген (алга таба – Үзәк) төзергә.

2. Үзәк федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф оешмаларының һәм фәнни оешмаларның икътисадның реаль секторында эшләүче оешмалар белән юридик зат оештырмыйча төзелгән берләшмәсе булып тора дип билгеләргә.

3. Үзәктә катнашучылар составын алар белән килештереп билгеләргә (1 нче кушымта).

4. Үзәкне яңа катнашучыларга аңа керү өчен ачык дип билгеләргә.

5. Үзәкнең Күзәтчелек советы турындагы нигезләмәне (2 нче кушымта) һәм аның составын (3 нче кушымта) расларга.

6. «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционер җәмгыятенә Үзәкнең Күзәтчелек советы эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне, шулай ук координатор һәм анда катнашучылар хезмәттәшлеге челтәрен берләштерүче функцияләрен гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционер җәмгыяте белән берлектә Үзәкнең күзәтчелек советына карап тикшерүгә түбәндәгеләр буенча тәкъдимнәр кертергә:

Үзәкнең проект офисы эшчәнлеге составы һәм регламенты;

Үзәкнең Идарә советы составы һәм нигезләмәсе;

югары белем бирү мәгариф оешмаларының һәм фәнни оешмаларның берләшүе һәм аларның икътисадның реаль секторында эшләүче оешмалар белән бергәләп гамәл кылуы нигезендә дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәкләренә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә грант алучы – коммерциячел булмаган оешманың нигезләмәсе.

8. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 24 февраль
№ ПУ-115

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «24 » февралендәге
ПУ- 115 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасында**
**дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәгендә катнашучылар**
**составы**

1. «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе.
2. «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе.
3. «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе.
4. «Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе.
5. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе.
6. «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе.
7. «Казан милли тикшеренү технологик университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе.
8. «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе.
9. «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе.
10. «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россиянең диплом алганнан соң белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өзлексез һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясе.
11. «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе.
12. «Кама инновацияле территориаль-җитештерү кластеры» коммерциячел булмаган партнерлыгы» ассоциациясе».
13. Татарстан Республикасы предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе).
14. «Нефть промыселы химиясе буенча фәнни-тикшеренү институты» акционер җәмгыяте.

15. «НӘФИС КОСМЕТИКС» акционер җәмгыяте – М. Вахитов исемендәге Казан химия комбинаты (Крестовниковларның элеккеге 1 номерлы сабын кайнату һәм шәм ясау заводы).

16. «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционер җәмгыяте.

17. «Связьинвестнефтехим» акционер җәмгыяте.

18. «ТАИФ» акционер җәмгыяте.

19. «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте.

20. «Татхимфармпрепараты» акционер җәмгыяте.

21. «Татэнерго» акционер җәмгыяте.

22. «Татэнергосбыт» акционер җәмгыяте.

23. «Челтәр компаниясе» ачык акционер җәмгыяте.

24. «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционер җәмгыяте.

25. «Казан Органик синтез» гавами акционер җәмгыяте.

26. «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте.

27. «Түбән Кама нефтехим» гавами акционер җәмгыяте.

28. В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте.

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «24» февралендәге
ПУ-115 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәгенең күзәтчелек советы турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәгенең күзәтчелек советы (алга таба – Күзәтчелек советы) Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәге (алга таба – Үзәк) белән идарә итүнең коллегиаль киңәшмә органы булып тора.

1.2. Күзәтчелек советы федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эшчәнлек алып бара.

2. Күзәтчелек советы эшчәнлегенең төп бурычлары һәм функцияләре

2.1. Үзәк эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыру һәм аның эшчәнлеге программасын билгеләү Күзәтчелек советының төп бурычлары булып тора.

2.2. Күзәтчелек советы үзенә йөкләнгән төп бурычларны гамәлгә ашыру өчен түбәндәге функцияләрне башкара:

Үзәк эшчәнлеге программасын раслау, шулай ук билгеләнгән тәртиптә аңа үзгәрешләр кертү һәм аның үтәлешен контрольдә тоту;

Үзәк эшчәнлеге программасын тормышка ашыруны мониторинглау;

Үзәкнең Идарә советы турында нигезләмәне һәм аның составын раслау, Үзәкнең башка консультатив һәм киңәшмә органнарын формалаштыру тәртибен, аның бурычларын һәм функцияләрен билгеләү;

Үзәк эшчәнлегенең программасын үтәү һәм аның нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында еллык хисапны раслау;

Үзәк эшчәнлеге программасында каралган башка функцияләрне үтәү.

2.3. Функцияләрен үтәү максатларында Үзәк проект офислары һәм башка эш төркемнәре төзергә хокуклы.

3. Күзәтчелек советы эшчәнлеген оештыру

3.1. Күзәтчелек советы составы федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, югары белем бирү мәгариф оешмалары, фәнни оешмалар һәм икътисадның реаль секторында эшләүче оешмалар вәкилләре арасыннан төзелә.

3.2. Күзәтчелек советы составына үз эшчәнлеген җәмәгать башлангычларда гамәлгә ашыручы Күзәтчелек советы рәисе, Күзәтчелек

советы рәисе урынбасарлары, Күзәтчелек советы секретаре һәм Күзәтчелек советы әгъзалары керә.

3.3. Күзәтчелек советын Күзәтчелек советы рәисе – Татарстан Республикасы Президенты җитәкли (алга таба – рәис).

3.4. Күзәтчелек советы утырышлары рәис кушуы буенча Күзәтчелек советы секретаре тарафыннан чакырыла. Күзәтчелек советы утырышлары, кирәк булуга карап, әмма елына кимендә бер тапкыр чакырыла.

3.5. Күзәтчелек советы утырышлары турыдан-туры катнашу формасында үткәрелә. Совет утырышы видео-конференц-элемтә системасын кулланып үткәрелергә мөмкин.

3.6. Күзәтчелек советы утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан күбесе катнашса, гамәлгә хокуклы дип санала.

3.7. Күзәтчелек советы утырышының көн тәртибе Күзәтчелек советы әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә формалаштырыла.

3.8. Күзәтчелек советы секретаре Күзәтчелек советы утырышын үткәрү көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча, рәискә Күзәтчелек советы утырышының көн тәртибе проектын, утырышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча документларны һәм мәгълүмати материалларны бирә.

3.9. Утырышның рәис тарафыннан расланган көн тәртибе, шулай ук утырыш көн тәртибе буенча документлар һәм мәгълүмати материаллар, утырышны уздыру көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Күзәтчелек советының башка әгъзаларына җибәрелә.

3.10. Күзәтчелек советы утырышларында чакырылган экспертлар, шулай ук Үзәкнең Идарә советы әгъзалары киңәш хокукы белән катнаша.

3.11. Күзәтчелек советы утырышында карарлар ачык тавыш бирү юлы белән, әлеге утырышта катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч була.

3.12. Күзәтчелек советы вәкаләтләрен Идарә советына, башка органнарга һәм затларга тапшыру рөхсәт ителми.

## 4. Күзәтчелек советы карарларын рәсмиләштерү тәртибе

4.1. Күзәтчелек советы утырышында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

4.2. Күзәтчелек советы утырышы беркетмәсе утырыш барышында Күзәтчелек советы секретаре тарафыннан алып барыла һәм рәис һәм Күзәтчелек советы секретаре тарафыннан имзалана. Күзәтчелек советының кабул ителгән карарга каршы тавыш биргән әгъзасының фикере аның таләбе буенча Күзәтчелек советы утырышы беркетмәсенә кертелә.

4.3. Күзәтчелек советы утырышы беркетмәсе утырыш үткәрелгән көннән биш көннән дә соңга калмыйча төзелә.

4.4. Күзәтчелек советы утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

утырышта катнашучы затлар һәм утырышта видео-конференц-элемтә куллану юлы белән катнашкан затлар турында мәгълүматлар;

утырышның көн тәртибе;

утырышта каралган һәр мәсьәлә буенча тавыш бирү нәтиҗәләре;

тавышларны санауны башкарган затлар турында мәгълүматлар;

Күзәтчелек советы карарын кабул итүгә каршы тавыш биргән һәм бу турыда язманы беркетмәгә кертүне таләп иткән затлар турында мәгълүматлар;

кабул ителгән карарлар.

4.5. Күзәтчелек советы утырышлары беркетмәләренең төп нөсхәләре сакланышын Күзәтчелек советы секретаре тәэмин итә. Беркетмәләргә хронологик тәртиптә номер сугыла, алар аерым эш итеп формалаштырыла һәм кулланылышы чикләнгән мәгълүматлы документлар булып тора.

4.6. Күзәтчелек советы утырышлары беркетмәләренең күчермәләре Күзәтчелек советы секретаре тарафыннан, Күзәтчелек советы утырышы үткәрелгән көннән алып 10 көннән дә соңга калмыйча, рәискә һәм Күзәтчелек советы әгъзаларына, шулай ук Үзәкнең Идарә советына җибәрелә.

4.7. Күзәтчелек советы секретаре Күзәтчелек советы утырышлары беркетмәләреннән күчермәләр әзерли һәм аларны Күзәтчелек советының тиешле карарлары үтәлешен тормышка ашыручы Үзәк вәкилләренә җибәрә.

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «24» февралендәге
ПУ-115 номерлы Указына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәгенең күзәтчелек советы составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов<br>Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Күзәтчелек советы рәисе |
| Боровская<br>Марина Александровна | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министры урынбасары, Күзәтчелек советы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Песошин<br>Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Күзәтчелек советы рәисе урынбасары |
| Яруллин<br>Рафинат Самат улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры, Күзәтчелек советы секретаре (килешү буенча) |
| Борһанов<br>Рафис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Гайзатуллин<br>Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Гафуров<br>Илшат Рәфкать улы | Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры, Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы рәисе (килешү буенча) |
| Җәббаров<br>Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |

| | |
|---|---|
| Кәримов<br>Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Когогин<br>Сергей Анатольевич | «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Мәганов<br>Наил Өлфәт улы | В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Садыйков<br>Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Сәлахов<br>Мәгъзүм Хәлимулла улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (килешү буенча) |
| Синяшин<br>Олег Герольдович | «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Сорокин<br>Валерий Юрьевич | «Связьинвестнефтехим» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Хәйруллин<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Шаһиәхмәтов<br>Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Шадриков<br>Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры |
| Шиһабетдинов<br>Руслан Альберт улы | «ТАИФ» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча). |